**Питрәч үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре**

**Методик-библиография бүлеге**



# Татар язучысы, шагыйрь Әнәс Кари улы Кариев 1920 -1954 ел

**Төзүче: баш библиограф**

**Павлова Н.И.**

**Питрәч-2020 ел**

Шагыйрь **Әнәс Кари** улы Кариев (Әнәс Кари) 1920 нче елда Татарстанның Азнакай районы Уразай авылында крестьян гаиләсендә туа.

1937 нче елда урта мәктәпне һәм 1939 нчы елда Үзбәкстандагы Үргәнеч укытучылар институтын тәмамлаганнан соң, шул ук институтның әзерлек курсларында ике ел укытучы булып эшли, аннары, туган якларына кайтып, 1942 нче елның җәенә кадәр урта мәктәптә укыта. Шул елның көзендә Әнәс Кари фронтка китә, Орлов тирәсендә барган канлы сугышларда катнаша һәм, каты яраланып, ахырда армия хезмәтеннән бөтенләй азат ителә.

Армиядән кайткач, Әнәс Кари берникадәр вакыт яңадан Үргәнеч укытучылар институтында укыта.


**1945 нче елдан гомеренең соңгы көненә хәтле Питрәч районы Янсуар авылы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияте укытучысы булып эшли.** Укыту дәверендә ул үзенең чын укытучы , балаларның яраткан укытучысы булуын күрсәтә.

**Әнәс Кари 1954 нче елның 4 нче апрелендә вафат була.** Әнәс Кари үзенең кыска иҗат гомерен балалар әдәбиятына багышлаган шагыйрь. Аның исеме вакытлы матбугатта Бөек Ватан сугышына хәтле үк күренә башлый. “Яшь Ленинчы» битләрендә беренче шигырьләре дөнья күрә.

Бөек Ватан сугышы елларында язган әсәрләре “Совет әдәбияте” журналында , “Кызыл Татарстан”газетасы битләрендә һәм фронт газеталарында басылып чыга. Аның “Балаларга бүләк” исемле беренче җыентыгы 1947 нче елда дөнья күрә.
Үзе исән чагында ул тагын өч- дүрт китабын чыгарырга өлгерә. Калган китаплары вафат булганнан соң дөнья күрә.

**Төп басма китаплары:**

Кари Ә. Балаларга бүләк: шигырьләр – Казан: Татгосиздат, 1947ел.
Кари Ә. Гөлбакча: шигырьләр-Казан: Татгосиздат, 1948 ел.
Кари Ә . Күңелле ел: шигырьләр - Казан:Татгосиздат,1951ел.
Кари Ә . Дуслык: шигырьләр- Казан: Татгосиздат, 1953ел.
Кари Ә. Беренче адымнар: шигырьләр- Казан: Таткнигоиздат, 1954 ел.
Кари Ә. Сыналган мәхәббәт: шигырьләр, поэмалар –Казан: Таткнигоиздат, 1956 ел.
Кари Ә. Тамчы тамганда : шигырьләр- Казан: Таткнигоиздат, 1957 ел.
Кари Ә. Хуш килдегез, кошлар!:шигырьләр- Казан:Татар кит. нәшр., 1966 ел.
Кари Ә. Тамчы һәм чишмә:шигырьләр- Казан:Татар. кит. нәшр., 1985 ел.
Кари Ә. Тамчы тамганда:балалар өчен шигырьләр - Казан: Татар. кит. нәшр.,1990 ел.
Кари Ә. Гөлбакча: шигырьләр - Казан:Татар.кит.нәшр., 1996 ел.



## ЧӘЧӘК ҖЫЯМ

Бакчага чыктым,
Чәчәкләр өзәм,
Иң матурларын
Бәйләмгә тезәм.

Менә ал чәчәк,
Нәкъ ялкын төсле,
Монсы зәп-зәңгәр,
Әйбәт, хуш исле.





## КЫШ

Юеш көннәрдә
Зарыгып беттек,
Кыш бабабызны
Сагынып көттек.

Без нәниләрне
Кыш та сагынган,
Төнлә килеп, ул
Карлар яудырган.

Кар яуган! Яуган
Мамык кебек кар,
Ап-ак булганнар
Урамнар, кырлар.

Бәскә төренгән
Агач башлары...
Бүгеннән безгә
Бәйрәм башланды!

Җыелып бергә,
Тауга чыгабыз,
Шаулашып анда
Чана шуабыз.

Кычкырабыз без
Бергәләп: «на! на!»
Курыкмыйбыз һич,
Чанабыз яңа.

**Әтием тракторчы**

Менеп утырды да әти
Көчле тракторына.
Бөтен урамны гөрләтеп
Китте колхоз кырына.

Рулне ныклап кысып тоткан,
Җибәрми кулларыннан.
Тракторның артына
Сабан, тырма тагылган.

Әти шулай кырга чыгып,
Көне буе җир сөрә.
Ул сөргән җирләр колхозга
Ел да мул уңыш бирә.

**Минем кунагым**

Зур бер бүләк алган сыман
Чын күңелдән куандым:
Сыерчык килде, сыерчык,
Сагынып көткән кунагым.

Хәзерләнеп тордым күптән
Каршыларга дип аны.
Әнә ничек яраткан ул
Мин ясаган ояны.

Тирәсендә очып йөргәч,
Кереп эчен карады:
Яңа өен котлагандай,
Матур итеп сайрады.